| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**18.12.2018** **№208**

Казан шәһәре

Дәүләт хезмәтендә булган гражданнарның тәртипләренә карата таләпләрнең үтәлүе һәм мәнфәгатьләр бәрелешен, низагларны көйләү буенча, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы комиссиясе утырышы уздыру өчен нигез булырдай мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр кабул итү тәртибе һәм турында карар

2010 елның 25нче августында кабул ителгән УП-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы буенча Дәүләт хезмәтендә булган гражданнарның тәртипләренә карата таләпләрнең үтәлүе һәм мәнфәгатьләр бәрелешен, низагларны көйләү буенча комиссияләр турында Нигезләмәнең 15нче пунктының «б» өлеше нигезендә, б о е р ы к бирәм:

1. Беркетелгән Дәүләт хезмәтендә булган гражданнарның тәртипләренә карата таләпләрнең үтәлүе һәм мәнфәгатьләр бәрелешен, низагларны көйләү буенча, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы комиссиясе

утырышы уздыру өчен нигез булырдай мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр кабул итү тәртибен расларга.

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт секторына Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтен башкаручы гражданнарны һәм министрлык белән билгеле-бер хезмәт башкару турында контрактлар төзегән затларны әлеге боерык белән таныштырырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **Д.И.Фаттахов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
боерыгы белән расланган
2018 елның 18 декабре № 208

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе утырышын үткәрүгә нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр нигезләмәсе

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба − Министрлык) дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе утырышын үткәрүгә нигез булып торучы мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр тәртибе (алга таба − тәртип) Министрлыкның дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлекчәсенә керү процедурасын регламентлаштыра:

гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән очракта, дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгән көннән соң ике ел узгач, коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләп торуга килешү турында;

дәүләт хезмәткәренең нигезле сәбәпләр буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге яки мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең, территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, акчалата акча чаралары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле сәбәпле, яки аның ихтыярына яки аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар булу сәбәпле, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча

чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең Министрлыкта вазифаи вәкаләтләрне башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында белдерүнамәсе 2018 елның 13 декабрендәге 190-пр номерлы Министрлык боерыгы белән ьайга салына

3. Гражданлык хезмәткәренең мөрәҗәгате һәм гаризалары 1, 2, 3 кушымталар нигезендә язма рәвештә төзелә һәм министрга җибәрелә.

4. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) өч эш көне эчендә Министрлыкның коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка мөрәҗәгать (гариза) җибәрә.

5. Комиссия, мөрәҗәгать (гариза), аңлатмалар һәм башка материалларны, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Министрлык комиссиясе турындагы Нигезләмә нигезендә карый.

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
хезмәт урынындагы тәртибенә карата
таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр
бәрелешен җайга салу комиссиясе
утырышын үткәрүгә нигез булып торучы
мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр
нигезләмәсенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрына
___________________________________
______________________________дан
(Ф.И.Аи., адресы, телефон номеры)
___________________________________

Гариза

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлеше, РФ Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы нигезендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясенә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының элеккеге хезмәткәре буларак мөрәҗәгать итәм ____________________________________________________

(дәүләт хезмәте вазыйфасының атамасы)

әлеге вазифаны башкару өчен ризалык алу максаты белән (гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкару)_____________________________________________

(вазыйфа, оешманың исеме)

Минем вазыйфаларым:________________________________________________________

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе утырышын шәхсән катнашырга исәп тотам/исәпләмим (тиешле ассызыкларга кирәк).

________________________ ________________________

(дата) (имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
хезмәт урынындагы тәртибенә карата
таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр
бәрелешен җайга салу комиссиясе
утырышын үткәрүгә нигез булып торучы
мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр
нигезләмәсенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрына
___________________________________
______________________________дан
(Ф.И.Аи., адресы, телефон номеры)
___________________________________

Гариза

Мин, ____________________________________________________________________
дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын башкаручы ___________________________
_____________________________________________________________________________
(вазифаның атамасы, бүлек)
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлекчәсенә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә бирү мөмкинлегем юк ___
_____________________________________________________________________________
(Ф. И. Аи. (соңгысы-булган очракта), хатыны, ире һәм (яки) балигъ булмаган балалары)
______ буенча ____ вакыт эчендә, ___________________________________ яшәүче.
(яшәү адресын тулысынча күрсәтергә)
түбәндәге объектив сәбәпләр буенча __________________________________________
_____________________________________________________________________________
(мәгълүматларны тапшырмауның конкрет сәбәпләре күрсәтелә)
Гаризага бәян ителгән мәгълүматны раслаучы түбәндәге өстәмә материалларны өстим (булган очракта):
_______________________________________________________

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе утырышын шәхсән катнашырга исәп тотам/исәпләмим (тиешле ассызыкларга кирәк).

________________________                ________________________

(дата) (имза) (имзаны аныклау)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
хезмәт урынындагы тәртибенә карата
таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр
бәрелешен җайга салу комиссиясе
утырышын үткәрүгә нигез булып торучы
мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм белдерүләр
нигезләмәсенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрына
___________________________________
______________________________дан
(Ф.И.Аи., адресы, телефон номеры)
___________________________________

Гариза

Мин, _______________________________________________________________________
дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын башкаручы ___________________________
______________________________________________________________________________
(вазифаның атамасы, бүлек)
2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегем булмавы турында хәбәр итәм ___________________________________
______________________________________________________________________________
(федераль закон таләпләрен үтәмәүнең конкрет сәбәпләре күрсәтелә)
Гаризага бәян ителгән мәгълүматны раслаучы түбәндәге өстәмә материалларны өстим (булган очракта): ____________________________________________________
Кабул ителгән чаралар:_________________________________________________________
(күрелгән чараларны санап чыгу)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе утырышын шәхсән катнашырга исәп тотам/исәпләмим (тиешле ассызыкларга кирәк).

______________________ ______________________

(дата) (имза) (имзаны аныклау)